**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 30 апрелендәге 1325 номерлы карары**

## 2025 елда иҗтимагый-сәяси чаралар әзерләү һәм уздыру чорында куркыныч йөкләр ташучы транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында

2025 елда иҗтимагый-сәяси чараларны әзерләү һәм уздыру чорында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү максатыннан, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә туктатуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә:

1. **Карар бирәм**:

1.1. Казан шәһәренең автомобиль юллары буйлап югары дәрәҗәдәге куркыныч матдәләр ташый торган транспорт чаралары хәрәкәтен һәм туктап торуларын чикләүне кертергә:

1.1.1. 2025 елның 8 маеннан алып 2025 елның 10 маена кадәр – 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгын бәйрәм итүгә багышланган чаралар кысаларында;

1.1.2. 2025 елның 13 маеннан алып 2025 елның 19 маена кадәр – «Россия – Ислам дөньясы: Kazan Forum» халыкара икътисадый форумы кысаларында;

1.1.3. 2025 елның 10 июненнән алып 2025 елның 14 июненә кадәр – «Киләчәкне формалаштырып» халыкара мәгариф министрлары форумы кысаларында;

1.1.4. 2025 елның 17 сентябреннән алып 2025 елның 19 сентябренә кадәр – Kazan Digital Week халыкара форумы кысаларында;

1.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров) Интернет челтәрендә «Татарстан Республикасының рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында мәгълүматны урнаштырырга;

1.3. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**2. Тәкъдим итәм:**

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Н.Д. Закиров) әлеге карар нигезендә юл хәрәкәте иминлеген саклауны һәм оештыру-көйләү гамәлләрен башкаруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

2.2. Казан шәһәр Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) әлеге карар нигезендә транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**